ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

28.09.2018 Казан ш. № 266

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2015 елның 5 февралендәге 29 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының Дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт тарафыннан җайга салынырга тиешле товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) бәяләренең (тарифларының, өстәмә түләүләрнең, өстәмә бәяләрнең) дөрес кулланылуы һәм аларның зурлыгының нигезләнгән булуы өлешендә дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының (алга таба – Дәүләт комитеты) норматив хокукый актын законнарга туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Дәүләт комитетының 2015 елның 5 февралендәге 29 номерлы боерыгы белән расланган (Дәүләт комитетының 2016 елның 9 мартындагы 50 номерлы, 2017 елның 31 гыйнварындагы 16 номерлы, 2017 елның 7 августындагы 190 номерлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының Дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт тарафыннан җайга салынырга тиешле товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) бәяләренең (тарифларының, өстәмә түләүләрнең, өстәмә бәяләрнең) дөрес кулланылуы һәм аларның зурлыгының нигезләнгән булуы өлешендә дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Дәүләт функциясе Дәүләт комитеты тарафыннан түбәндәгеләр нигезендә башкарыла:

Россия Федерациясе Граждан кодексы (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 1994, № 32, ст.3301, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы (алга таба - КоАП РФ) (Российская газета, 2001, 31 декабрь, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Су кодексы (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2006, № 23, ст.2381, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Урман кодексы (Российская газета, 2006, 8 декабрь, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Табигый монополияләр турында» 1995 елның 17 августындагы 147-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 1995, № 34, ст. 3426, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 1998, № 26, ст. 3009, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы 69-ФЗномерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 1999, № 14, ст. 1667, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» 2003 елның 10 гыйнварындагы 17-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2003, № 2, ст. 169, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2003, № 13, ст. 1177, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 59-ФЗ номерлы Федераль закон) (Российская газета, 2006, 5 май, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 294-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2008, № 52, ст. 6249, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Дару чараларының әйләнеше турында» 2010 елның 12 апрелендәге 61-ФЗ номерлы Федераль закон (Российская газета, 2010, 14 апрель, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон (Российская газета, 2010, 30 июль, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Транспорт чараларының техник ягын тикшерү турында һәм «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 1

июлендәге 170-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2011, № 27, ст. 3881, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу турында»
2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон (Российская газета, 2011, 22 июль, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон (Рәсми хокукый мәгълүмат интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2011, 8 декабрь, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2013, № 52, ст. 7007, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Президентының «Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 28 февралендәге 221 номерлы Указы (Российские вести, 1995, 3 март, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышына дәүләт күзәтчелеге турында» 1993 елның 13 декабрендәге 1291 номерлы карары (Россия Федерациясе Президенты һәм Хөкүмәте актлары җыентыгы, 1993, № 51, ст. 4943, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 1995, № 11, ст. 997, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Газ һәм аны җитештерү өчен чимал бәяләрен дәүләт тарафыннан җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 15 апрелендәге 332 номерлы карары (Российская газета, 1995, 21 апрель, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә торак фондын дәүләт исәбенә алу турында» 1997 елның 13 октябрендәге 1301 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 1997, № 42, ст. 4787, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе территориясендә газ бәяләрен, аны транспортировкалау буенча хезмәт күрсәтүләргә тарифларны һәм газ белән эшли торган җиһазларны газ бүлеп җибәрү челтәрләренә технологик тоташтырган өчен түләүне дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2000 елның 29 декабрендәге 1021 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2001, № 2, ст. 175, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергиясен тапшыру буенча хезмәтләр күрсәтүдән һәркемнең дискриминациясез файдалану һәм әлеге хезмәтләрне күрсәтү кагыйдәләрен, Электр энергетикасында оператив-диспетчерлык идарә итүе буенча хезмәтләр күрсәтүдән һәркемнең

дискриминациясез файдалану һәм әлеге хезмәтләрне күрсәтү кагыйдәләрен, Күмәрләп сату базарының сәүдә системасы администраторының хезмәтләр күрсәтүеннән һәркемнең дискриминациясез файдалану һәм әлеге хезмәтләрне күрсәтү кагыйдәләрен һәм Электр энергиясен кулланучыларның электрдан эшли торган җайланмаларын, электр энергиясен җитештерү объектларын, шулай ук электр челтәрләре оешмаларына һәм башка затларга караган электр челтәре хуҗалыгы объектларын электр челтәрләренә технологик тоташтыру кагыйдәләрен раслау турында» 2004 елның 27 декабрендәге 861 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2004, № 52, ст. 5525, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Транспорт терминалларында, портларда, аэропортларда табигый монополияләр субъектларына хезмәтләр күрсәтүгә һәм эчке су юллары инфраструктурасыннан файдалану буенча хезмәтләр күрсәтүгә бәяләрне (тарифларны, җыемнарны) дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2008 елның 23 апрелендәге 293 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2008, № 17, ст. 1887, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимиятенең тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендәге органнарының табигый монополияләр субъектлары эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салуны һәм тикшереп торуны гамәлгә ашыруда катнашуы турында» 2008 елның 10 декабрендәге 950 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2008, № 50, ст. 5971, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Яшәү өчен кирәкле һәм иң мөһим дару препаратлары исемлегенә кертелгән дару препаратлары бәяләрен дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2010 елның 29 октябрендәге 865 номерлы карары (Российская газета, 2010, 3 ноябрь, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Транспорт чараларының техник ягына тикшерү уздыру турында» 2011 елның 5 декабрендәге 1008 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2011, № 50, ст. 7397, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасында җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя кую турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2012, № 4, ст. 504, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергиясен ваклап сату базарларының эшләве, электр энергиясен куллану режимын тулысынча һәм (яки) өлешчә чикләү турында» 2012 елның 4 маендагы 442 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2012, № 23, ст. 3008, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2012, № 44, ст. 6022, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары (Рәсми хокукый мәгълүмат интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2013, 15 май, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) турында, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү һәм кайберләренең үз көчләрен югалтуларын тану хакында» 2013 елның 27 июнендәге 543 номерлы карары (Рәсми хокукый мәгълүмат интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2013, 1 июль, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләрнең бердәм реестрын төзү һәм алып бару кагыйдәләре турында» 2015 елның 28 апрелендәге 415 номерлы карары (алга таба - Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 28 апрелендәге 415 номерлы карары) (Рәсми хокукый мәгълүмат интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2015, 7 май, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләр оештырылганда һәм үткәрелгәндә дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан тиешле документлар һәм (яки) мәгълүмат булган башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан йә дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары буйсынуындагы оешмалардан ведомствоара мәгълүмат алмашу кысаларында түләүсез нигездә, шул исәптән электрон рәвештә, документлар һәм (яки) мәгълүмат соратып алу турында» 2016 елның 18 апрелендәге 323 номерлы карары (Рәсми хокукый мәгълүмат интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2016, 20 апрель );

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә бәя кую турында» 2016 елның 30 маендагы 484 номерлы карары (Рәсми хокукый мәгълүмат интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2016, 3 июнь, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Мәҗбүри таләпләрне бозуның ярамавы турында искәртүне төзү һәм юллау, мондый искәртүгә юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан ризасызлыклар белдерү һәм аларны карау, мондый искәртүне үтәү турында хәбәр итү кагыйдәләрен раслау хакында» 2017 елның 10 февралендәге 166 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 10 февралендәге 166 номерлы карары) (Рәсми хокукый мәгълүмат интернет-порталы , (www.pravo.gov.ru), 2017, 14 февраль);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Документларга һәм (яки) мәгълүматка ия башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яисә дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары буйсынуындагы оешмалар тарафыннан тикшерүләр оештырылганда һәм үткәрелгәндә, дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары ведомствоара мәгълүмат алмашу эшчәнлеге кысаларында соратып ала торган документлар һәм (яки) мәгълүмат исемлеген раслау турында» 2016 елның 19 апрелендәге 724-р номерлы күрсәтмәсе (Рәсми хокукый мәгълүмат интернет-порталы, (www.pravo.gov.ru), 2016, 22 апрель кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру хакында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы (алга таба - Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы) (Российская газета, 2009, 14 май, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Ватаным Татарстан, 2008, 28 май, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Тоткарланган транспорт чараларын махсуслаштырылган урынга күчерү, аларны саклау, кире кайтару, күчергән һәм саклаган өчен чыгымнарны түләү тәртибе турында» 2012 елның 17 маендагы 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Республика Татарстан, 2012, 26 май, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 елның 18 декабрендәге 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Республика Татарстан, 2014, 20 декабрь, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законны гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Республикасының Рәсми хокукый мәгълүмат порталы (pravo.tatarstan.ru), 2015, 28 декабрь, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2010 елның 15 июнендәге 468 нче карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарлары һәм күрсәтмәләре һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы» журналы, 2010, № 29, ст. 1195, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында Транспорт чараларына техник тикшерү уздырган өчен түләүнең чик күләмнәрен билгеләү турында» 2011 елның 27 декабрендәге 1079 номерлы карары (Республика Татарстан, 2011, 31 декабрь, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр тарафыннан социаль хезмәтне өйдә күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләрне күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 елның 29 декабрендәге 1053 номерлы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарлары һәм күрсәтмәләре һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы, 2015, № 7–8, 0201, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2017 елның 5 августындагы 555 номерлы карары (Татарстан Республикасының Рәсми хокукый мәгълүмат порталы (pravo.tatarstan.ru), 2017, 7 август, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).»;

1.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.7. Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда Дәүләт комитетының вазыйфаи затлары хокуклары, бурычлары һәм алар өчен чикләүләр.»;

1.9 пунктның унынчы абзацында «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән» сүзләрен «59-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән» сүзләренә алмаштырырга;

2.4.2 пунктның 3 пунктчасында «Россия Федерациясе Хөкүмәте тиешле өлкәдә вәкаләтләр биргән федераль башкарма хакимият органы» сүзләрен «тиешле эшчәнлек өлкәсендә вәкаләтләр бирелгән дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы» сүзләренә алмаштырырга»;

3 бүлекнең 1 нче таблицасында:

6 пунктның 4 юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» 2003 елның 10 гыйнварындагы 17-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы 2.1 өлеше, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 номерлы карары»;

12 пунктның 4 юлында «Коммуналь комплекс оешмалары тарифларын җайга салу нигезләре турында» 2004 елның 30 декабрендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон; Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Коммуналь комплекс оешмалары эшчәнлеге өлкәсендә бәя кую нигезләре һәм тарифларны, өстәмә түләүләрне һәм чик индексларны җайга салу тәртибе турында» 2008 елның 14 июлендәге 520 номерлы карары;» сүзләрен төшереп калдырырга;

21 пунктта:

2 юлда «шул исәптән техник ягын диагностикалау чараларын кулланып» сүзләрен «диагностика картасының дубликатын бирү» сүзләренә алмаштырырга;

4 юлда «16 статья» сүзләреннән соң «19 статьяның 9 өлеше» сүзләрен өстәргә;

22 пунктның 4 юлында «2006 елның 3 июнендәге 74-ФЗ номерлы» сүзләрен төшереп калдырырга;

23 пунктның 4 юлында һәм алга таба текст буенча «2006 елның 4 декабрендәге 200-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Урман кодексының 82 статьясы» сүзләрен «Россия Федерациясе Урман кодексының 82 статьясы» сүзләренә алмаштырырга;

4 бүлекнең 2 нче таблицасында:

1.6 пунктның 3 юлында «2015 елның 24 ноябрендәге 563 номерлы Росстат боерыгы» сүзләрен «2017 елның 30 ноябрендәге 799 номерлы Росстат боерыгы» сүзләренә алмаштырырга;

2.4 пунктның 3 юлында «2016 елның 2 августындагы 379 номерлы Росстат боерыгы» сүзләрен «2017 елның 1 сентябрендәге 566 номерлы Росстат боерыгы» сүзләренә алмаштырырга;

2.12 пунктны үз көчен югалткан дип таныйрга;

7 пунктның 2 юлында «техник тикшерү талоны дубликатын бирү» сүзләрен «диагностика картасы дубликатын бирү» сүзләренә алмаштырырга;

7.2 пунктның 2 графасында «талон» сүзен төшереп калдырырга;

5.2.11 пунктчада һәм алга таба текст буенча «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләрнең бердәм реестрын булдыру һәм алып бару кагыйдәләре турында» 2015 елның 28 апрелендәге 415 номерлы карары» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 28 апрелендәге 415 номерлы карары сүзләренә алмаштырырга;

7 нче бүлектә:

7.4 пунктка түбәндәге эчтәлекле 7.4.1 һәм 7.4.2 пунктчалар өстәргә: «7.4.1. Гариза бирүче үзенең язма шикаятендә мәҗбүри рәвештә я язма гариза җибәрелә торган дәүләт органы (Дәүләт комитеты) исемен, я тиешле вазыйфаи затның фамилиясен, исемен, атасының исемен, я тиешле затның вазыйфасын, шулай ук үзенең фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы – булган очракта), җавап, шикаятьнең икенче адрес буенча юллануы турында хәбәрнамә җибәрелергә тиешле почта адресын күрсәтә, шикаятьнең асылын бәян итә, шәхси имзасын һәм дата куя.

Үзенең дәлилләрен раслау таләп ителгән очракта, гариза бирүче язма шикаятькә документлар һәм материаллар йә аларның күчермәләрен беркетеп тапшыра.

Дәүләт комитетына яки вазыйфаи затка электрон документ рәвешендә кергән шикаять 59-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш. Шикаятьтә гариза бирүче мәҗбүри рәвештә үзенең фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы – булган очракта), җавап, шикаятьнең икенче адрес буенча юллануы турында хәбәрнамә җибәрелергә тиешле электрон почта адресын күрсәтә. Гариза бирүче мондый шикаятькә электрон рөвештәге кирәкле документларны һәм материалларны беркетергә хокуклы.

7.4.2. Шикаятькә җавап Дәүләт комитетына яки Дәүләт комитетының вазыйфаи затына электрон документ рәвешендә кергән шикаятьтә күрсәтелгән электрон почта адресына электрон документ рәвешендә һәм Дәүләт комитетына яки Дәүләт комитетының вазыйфаи затына язма рәвештә кергән шикаятьтә күрсәтелгән почта адресына язма рәвештә җибәрелә. Моннан тыш, Дәүләт комитетына яки Дәүләт комитетының вазыйфаи затына билгесез затлар даирәсе мәнфәгатьләренә кагылышлы шикаятькә, аерым алганда, билгесез затлар даирәсенә карата чыгарылган суд карарына ризасызлык белдерелгән шикаятькә җавап, шул исәптән суд карарына ризасызлык белдерү тәртибе аңлатылган җавап, 59-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 2 өлеше таләпләрен үтәп, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Дәүләт комитеты рәсми сайтына куелырга мөмкин.

7.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.5. Әгәр язма шикаятьтә юридик затның исеме (гариза юллаучы юридик зат

булса), шикаять юллаган гариза бирүченең фамилиясе яки җавап җибәрелергә тиешле почта адресы күрсәтелмәгән булса, шикаятькә җавап бирелми. Әгәр күрсәтелгән шикаятьтә әзерләнә торган, башкарыла торган яки башкарылган хокукка каршы гамәлләр турында, шулай ук аны әзерләгән, башкара торган яки башкарган зат турында белешмәләр булса, шикаять дәүләт органына аның компетенциясенә туры китереп җибәрелергә тиеш.

Суд карарына ризасызлык белдерелгән шикаять теркәлгән көннән алып җиде көн эчендә, әлеге суд карарына ризасызлык белдерү тәртибе аңлатылып, гариза бирүчегә кире кайтарыла.

Әгәр язма шикаятьтә цензурасыз йә вазыйфаи затның, шулай ук аның гаилә әгъзаларының гомеренә, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә карата хурлау сүзләре, янаулар булса, шикаятькә анда куелган сорауларның асылы буенча җавап бирелмәскә мөмкин. Шикаять юллаган гариза бирүчегә бу очракта хокуктан явыз ният белән кулланның ярамавы турында хәбәр ителә.

Әгәр язма шикаятьнең тексты укырлык булмаса, шикаятькә җавап бирелми, һәм ул дәүләт органына, җирле үзидарә органына яки вазыйфаи затка аларның компетенциясенә туры китереп җибәрелми, әгәр шикаятьне юллаган гариза бирүченең фамилиясе һәм почта адресы укырлык булса, аңа шикаятьне теркәгән көннән алып җиде көн эчендә бу хакта хәбәр ителә.

Әгәр язма шикаятьнең тексты шикаятьнең асылын билгеләргә мөмкинлек бирмәсә, шикаятькә җавап бирелми, һәм ул дәүләт органына, җирле үзидарә органына яки вазыйфаи затка аларның компетенциясенә туры китереп җибәрелергә тиеш түгел, бу хакта шикаятьне теркәгән көннән алып җиде көн эчендә шикаятьне юллаган гариза бирүчегә хәбәр ителә.

Әгәр гариза бирүченең язма шикаятендә аңа элек җибәрелгән шикаятьләренең асылына бәйле рәвештә берничә тапкыр язма җавап җибәрелгән булса, һәм шул ук вакытта шикаятьтә яңа дәлилләр һәм шартлар китерелмәсә, Дәүләт комитеты рәисе, Дәүләт комитетының вазыйфаи заты йә моңа вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи заты шикаять белән чираттагы мөрәҗәгать итүнең нигезсез булуы һәм әлеге мәсьәлә буенча гариза бирүче белән язышуны туктату турында карар кабул итәргә хокуклы, тик бу очракта күрсәтелгән шикаять һәм элек юлланган шикаятьләр Дәүләт комитетына юлланган булырга тиеш. Әлеге карар турында шикаять юллаган гариза бирүчегә хәбәр ителә.

Әгәр Дәүләт комитетына яки Дәүләт комитетының вазыйфаи затына 59-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 4 өлеше нигезендә җавабы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Дәүләт комитетының рәсми сайтына урнаштырылган сорауны үз эченә алган язма шикаять кергән очракта, шикаять юллаган гариза бирүчегә шикаятьне теркәгән көннән алып җиде көн эчендә Дәүләт комитетының шикаятьтә куелган сорауга җавап урнаштырылган рәми сайтының электрон адресы хәбәр ителә, бу очракта суд карарына шикаять белдерүне үз эченә алган шикаять кире кайтарылмый.

Әгәр шикаятьтә куелган сорауның асылы буенча җавапны дәүләт серен яки федераль закон белән саклана торган башка серне тәшкил иткән мәгълүматны фаш итмичә генә бирү мөмкин булмаса, шикаять юллаган гариза бирүчегә, күрсәтелгән

мәгълүматларны фаш итәргә ярамаганга күрә, анда куелган сорауның асылы буенча җавап бирүнең мөмкин булмавы турында хәбәр ителә.

Шикаятьтә куелган сорауларның асылы буенча җавап бирелә алмаган сәбәпләр алга таба бетерелсә, гариза бирүче Дәүләт комитетына яки аның вазыйфаи затына кабат шикаять юллый ала.».

2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Рәис М.Р.Зарипов